# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## 1998 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында

**1 с т а т ь я.** 1998 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын чыгымнар буенча - 13048568 мең сум күләмендә һәм керемнәр буенча 12081681 мең сум күләмендә расларга.

1998 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 966887 мең сум күләмендә билгеләргә.

**2 с т а т ь я.** 1998 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәре өстәлгән бәяләргә салым, акцизлар, предприятиеләр һәм оешмалар табышына салымның бер өлеше, физик затлардан керем салымының бер өлеше, башка салым түләүләре һәм җыемнар, максатчыл бюджет фондлары акчалары исәбеннән барлыкка килә, дип билгеләргә.

**3 с т а т ь я.** Промышленность предприятиеләре су хуҗалыгы системаларыннан ала торган су өчен 1997 елның 31 декабренә гамәлдә булган түләү 2 коэффициенты белән алына, дип билгеләргә.

1998 елда җир өчен салымны исәпләгәндә 1997 елда гамәлдә булган ставкаларны кулланырга.

**4 с т а т ь я.** Товарларын ваклап сатучы, халыкка түләүле хезмәт күрсәтүче һәм түләүле эшләр башкаручы предприятиеләрдән һәм эшкуарлардан 1998 елның 1 гыйнвареннан башлап ваклап сатулар өчен салым алуны кертергә. Салым алкоголь продукциясе буенча 5 процентлы ставка, башка товарлар буенча - сатылган товарлар, күрсәтелгән хезмәтләр һәм башкарылган эшләр күләменнән 3 процентлы ставка буенча алына.

5 **с т а т ь я.** 1998 елга файдалы казылмаларны чыгарган өчен түләү ставкаларын чыгарылган табигый байлыкны сату бәясенә карата түбәндәге процентларда билгеләргә (моңа өстәлгән бәяләргә салым һәм акцизлар керми):

| т/с | Файдалы казылмаларның (чималның) төрләре | Ставка |
|---|---|---|
| 1. | Нефть һәм газ | 6 |
| 2. | Табигый битум | 4 |
| 3. | Гипс ташы | 4 |
| 4. | Фосфоритлар | 4 |
| 5. | Цемент чималы | 4 |
| 6. | Туфракны известьлау өчен карбонат токымнары | 3 |
| 7. | Карбонат токымнары | 3 |
| 8. | Киселгән таш | 3 |
| 9. | Бут һәм вак таш өчен төзелеш ташы | 3 |
| 10. | Ком-гравий катнашмасы | 4 |
| 11. | Пыяла һәм формалау комы | 4 |
| 12. | Төзелеш комы | 3 |
| 13. | Бентонит балчыклары | 4 |
| 14. | Керамзит балчыклары | 4 |
| 15. | Кирпеч балчыклары | 2,5 |
| 16. | Глауконитлар, цеолитлар | 4 |
| 17. | Торф, торфовивианит | 3 |
| 18. | Җир асты сулары | 6 |

1998 елда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр бюджет дәрәҗәләре буенча түбәндәгечә бүленә, дип билгеләргә (процентларда):

| Түләүләрнең төрләре | Бюджетлар буенча бүленеш | |
|---|---|---|
| | республика | районнар (шәһәрләр) |
| 1. Файдалы казылмаларны чыгарган өчен түләүләр | | |
| - торф, сапропель, җир асты сулары һәм минераль сулар буенча; | - | 100 |
| - гомум таралган файдалы казылмалар буенча; | - | 100 |
| - нефть, газ, Идел һәм Кама елгалары үзәннәреннән чыгарылучы ком-вак таш катнашмасы, табигый битум,гипс ташы, цемент чималы буенча; | 70 | 30 |
| - файдалы казылмаларның калган төрләре буенча (фосфоритлар,бентонит балчыклары, керамзит балчыклары,тәзелеш известе өчен карбонат токымнары, киселгөн таш, пыяла һәм формалау комы, глауконитлар, цеолитлар) | - | 100 |
| 2. Файдалы казылмаларны лицензияләрдә билгеләнгән лимитлардан (квоталардан) тыш кулланган өчен түләүләр 5 мәртәбәгә арттырылган ставка буенча алына; | 60 | 30 |
| - нормативлардан тыш кулланылыш билгеләгән орган исәп-хисабына - 10 процент | | |
| 3. Файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган җир куеныннан файдаланган өчен түләүләр | 50 | 50 |

6 с т а т ь я. Дәүләт мәлкәтен һәм коммуналь мөлкәтне хосусыйлаштырудан килгән акчалар, реинвестицияләүгә җибәрүне исәпкә алып, төрле дәрәҗәдәге бюджетлар һәм хосусыйлаштыру фондлары арасында түбәндәге нормативлар буенча бүленә:

а) фондлар һәм бюджет арасында:

(процентларда)

| | Хосусыйлаштыру фондларына | Татарстан Республикасы бюджетына |
|---|---|---|
| Хосусыйлаштырудан алынган акчаларның гомуми суммасы | 10 | 90 |

б) төрле дәрәҗәдәге бюджетлар арасында:

(процентларда)

| Объектларны хосусыйлаштырудан | Татарстан Республикасының республика бюджетына | Җирле бюджетларга |
|---|---|---|
| республика милкен | 70 | 30 |
| коммуналь милекне | 30 | 70 |

7 с т а т ь я. Предприятиеләрнең, оешмаларның Татарстан Республикасы бюджәтына кертелүче табышына (керемена) салым ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

а) предприятиеләр, оешмалар һәм чит илләрнең юридик затлары өчен – 22 процент күләмендә;

б) предприятиеләр өчен – арадашчы гамәлләреннән, сәүдә килешүләреннән алынган табыш буенча, биржалар, брокер конторалары, банклар, кредит һәм иминият оешмалары өчен – 30 процент күләмендә.

8 с т а т ь я. Предприятиеләрнең, оешмаларның һәм чит ил юридик затларының мөлкәткә салым буенча ставкасын салым салынучы базаның 2 проценты күләмендә билгеләргә.

1998 елда физик затларның мөлкәтенә салым ставкасын корылмаларның, биналарның, төзелмәләрнең инвентаризация хакының 0,1 проценты күләмендә билгеләргә.

9 с т а т ь я. "Татнефть" акционерлык җәмгыятенең өстәмә нефть чыгаруын кызыксындыру максатларында:

1. Нефтьнең һәр тоннасына акциз җыемнарын 15 сумга кадәр киметү, чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләүнең Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә 50 процентка киметү исәбенә, Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә, предприятиеләр мөлкәтенә, зыянга эшләүче аз дебитлы һәм күп сулы скважиналардан нефть чыгаруны тәэмин итүче скважиналарга, төп фондларга салымнан азат итү исәбенә зыянга эшләүче аз дебитлы һәм күп сулы скважиналардан 5779 мең тонна нефть чыгарырга.

2. Нефть бирүчәнлекне арттыруның яңа (гидродинамик, физик-химик, җылылык, газ, геологик-физик һәи микробиологик) алымнарын куллану исәбенә 906 мең тонна нефть чыгарырга - һәр тоннасына акциз җыемнарын 15 сум күләмендә билгеләргә, җир куены өчен түләүдән һәм Татарстан Республикасының минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүдән азат итәргә.

3. һәр тонна нефть өчен акциз җыемы ставкасын 25 сумга кадәр киметү, җир куены өчен түләүдән һәм Татарстан Республикасының минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларын чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүләрдән азат итү исәбенә яңа ятмалардан 1200 мең тонна нефть чыгарырга.

10 с т а т ь я. Татарстан Республикасының нефть чыгаручы башка компанияләрен өстәмә рәвештә нефть чыгаруга кызыксындыру максатларында:

1. Нефтьнең һәр тоннасына акциз җыемнарын 15 сумга кадәр киметү, чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләүнең Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә 50 процентка киметү исәбенә, Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә, предприятиеләр мөлкәтенә, зыянга эшләүче аз дебитлы һәм күп сулы скважиналардан

нефть чыгаруны тәэмин итүче скважиналарга, төп фондларга салымнан азат итү исәбенә зыянга эшләүче аз дебитлы һәм күп сулы скважиналардан 221 мең тонна нефть чыгарырга.

2. Нефть бирүчәнлекне арттыруның яңа (гидродинамик, физик-химик, җылылык, газ, геологик-физик һәм микробиологик) алымнарын куллану исәбенә 1971 мең тонна нефть чыгарырга – һәр тоннасына акциз җыемнарын 15 сум күләмендә билгеләргә, җир куены өчен түләүдән һәм Татарстан Республикасының минераль ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүдән азат итәргә.

3. һәр тонна нефть өчен акциз җыемы ставкасын 25 сумга кадәр киметү исәбенә яңа ятмалардан 618 мең тонна нефть чыгарырга, җир асты байлыклары өчен түләүдән, Татарстан Республикасының минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүдән азат итәргә.

11 статья. Минераль ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру өчен түләү ставкасын чыгарылган нефтьне сату бәяләренә карата 8 процент күләмендә билгеләргә (моңа өстәлгән бәяләргә салым һәм акцизлар керми).

12 статья. "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсенең (АлАЗ ЖБ) җиңел автомобильләр җитештерү куәтләре булдыруын дәүләт тарафыннан яклау максатларында, шулай ук "КамАЗ" ААҖен якын араларда зыянсыз эшләүгә ирештерү, аның түләү сәләтен торгызу, Чаллы шәһәрендә һәм аның тирәсендәге икътисадый зонада икътисадый вәзгыятьне савыктыру максатларында:

1. "АлАЗ-ДМ корпорациясе" уртак предприятиесен, "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсен һәм аның юридик зат хокуклары булган структур бүлекчәләрен табышка салымның Татарстан Республикасы республика бюджетына түләнә торган өлешеннән азат итәргә.

2. "АлАЗ-ДМ корпорациясе" уртак предприятиесе, "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсе һәм аның юридик зат хокукы булган структур бүлекчәләре җитештерүче товар-

ларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) өстәлгән бәяләргә салымның Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелүче өлешен түләүдән азат итәргә, шушы акчаларны җиңел автомобильләр җитештерү буенча яңа куәтләр булдыруны финанслауга тотарга.

3."АлАЗ-ДМ корпорациясе" уртак предприятиесе һәм "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсе җитештерүче җиңел автомобильләргә акциз ставкасын сатып җибәрү бәясенең 0,1 проценты күләмендә билгеләргә.

4. "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсенә, "АлАЗ-ДМ корпорациясе" уртак предприятиесенә һәм "КамАЗ" ААҖенә мөлкәткә салым ставкасын салым салу базасының 0,1 проценты күләмендә билгеләргә.

5. "КамАЗ" ААҖенә һәм әлеге ААҖ үз мөлкәтләренең 50 һәм һәм аннан да күбрәк процентына ия булган предприятиеләргә Татарстан Республикасының республика максатчыл бюджет фондларына (Халыкны эш белән тәэмин итү фондыннан һәм сырхауханә кассасыннан гайре) түләүләр буенча инвестиция салым кредиты бирергә.

6. "КамАЗ" ААҖ өчен комплектлаучы әйберләр җитештерүче предприятиеләргә республика бюджетына күчерелүче өлешендә табышка салым һәм өстәлгән бәяләргә салым буенча "КамАЗ" ААҖенә поставкалар күләмендә инвестиция салым кредиты бирергә, бу чакта исәп-хисап аерым-аерым алып барылу шарт.

13 с т а т ь я . 1998 елда Татарстан Республикасының республика бюджетына түбәндәге максатчыл бюджет фондларының акчаларын тупларга (кертергә):

Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды

Татарстан Республикасы "Янгын куркынычсызлыгы" фонды

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының ДАИ идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге фонды

Татарстан Республикасы Юллар фонды

Татарстан Республикасы Экология фонды

Татарстан Республикасы Хосусыйлаштыру фонды

Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә - конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фонды

Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды

Республика сырхауханә кассасы
Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру фонды

14 с т а т ь я. 1998 елга Татарстан Республикасының республика бюджетына төп чыганаклар буенча керемнәрнең килерен түбәндәге суммаларда исәпләргә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Салым керемнәре - барлыгы | 5349483 |
| шул исәптән: | |
| - предприятиеләр һәм оешмалар табышына (керемenә) салым | 756768 |
| - физик затлардан керем салымы | 68060 |
| - өстәлгән бәяләргә салым | 1690221 |
| - акцизлар | 1150000 |
| - лицензия җыемнары | 200000 |
| - предприятиеләр мөлкәтенә салым | 645786 |
| - табигый байлыклардан файдаланган өчен түләүләр | 574104 |
| - җир салымы һәм җир өчен аренда түләве | 152812 |
| - башка салымнар, җыемнар һәм пошлиналар | 101732 |
| - чит илләрнең акчаларын, чит ил валютасында белдерелгән түләү документларын сатып алган өчен салым | 10000 |
| Салымга карамаган керемнәр - барлыгы | 1004228 |
| шул исәптән: | |
| - дәүләт милкендәге мөлкәттән яки эшчәнлектән килгән керемнәр | 554228 |
| - 1997 елда кире кайтару шарты белән бирелгән акчаларның килере | 400000 |
| - салымга карамаган башка керемнәр, штрафлар,китерелгән зыянны түләттерү | 50000 |

| | |
|---|---|
| - Максатчыл бюджет фондлары керемнәре - барлыгы, | 5727970 |
| шул исәптән: | |
| Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды | 453700 |
| Татарстан Республикасы "Янгын куркынычсызлыгы" фонды | 90000 |
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының ДАИ идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 30000 |
| Татарстан Республикасы Юллар фонды | 2500000 |
| Татарстан Республикасы Экология фонды | 300000 |
| Татарстан Республикасы Хосусыйлаштыру фонды | 112000 |
| Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең республика (НИОКР) фонды | 552000 |
| Татарстан Республикасының минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 1130230 |
| Республика Сырхауханә кассасы | 140040 |
| Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру фонды | 420000 |

**15 с т а т ь я.** Татарстан Республикасының эчке дәүләт бурычының иң чик күләмен 1998 елда 1700000 мең сум, дип билгеләргә.

1998 елда Татарстан Республикасының тышкы дәүләт бурычының иң чик күләмен 2600000 мең сумга тигез, дип билгеләргә.

**16 с т а т ь я .** 1998 елда Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан эмиссияләнүче республика облигацияләрен эмиссияләүнең иң чик күләмен сумнарга күчереп исәпләгәндә, 1300000 мең сум, дип билгеләргә. 1998 елда Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан эмиссияләнүче республика облигацияләрен эмиссияләүнең иң чик күләмен чит ил валютасында

2500000 мең сумга тигез, дип билгеләргә.

17 с т а т ь я. Салым һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча 1998 елда Татарстан Республикасының республика бюджетына керә торган өлешендә бирелгән кичектерүләр (көтәчәкләр)өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының өчтән икесе күләмендә бюджет акчаларыннан файдаланган өчен процентлар рәвешендә түләү алына, дип билгеләргә.

18 с т а т ь я . 1998 елда Татарстан Республикасы территориясеннән Федераль бюджетка түләүләрне, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтләре арасында төзелгән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасында бюджет мөнәсәбәтләре хакындагы килешүне исәпкә алып, "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләрне чикләү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырырга.

19 с т а т ь я. 1998 елда район һәм шәһәр бюджетларына түбәндәге салымнарны тапшырырга:

- предприятиеләрнең һәм оешмаларның табышына (кеременә) салым - салым салынучы табышның 22 проценты күләмендә бирелә, ә түбәндәгеләргә:

Әлмәт районына һәм шәһәренә - 5 процент, Баулы районына һәм шәһәренә - 21 процент, Зәй районына һәм шәһәренә - 20 процент, Сарман районына - 13 процент, Тукай районына - 9 процент, Түбән Кама шәһәренә - 11 процент;

- физик затлардан предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда тотылып калучы керем салымы 11 процентлы ставка буенча, ә түбәндәгеләргә:

Әлмәт районына һәм шәһәренә - 74 процент, Зәй районына һәм шәһәренә - 70 процент;

- предприятиеләрнең мөлкәтенә салым 100 процент күләмен-

дә, ә түбәндәгеләргә:

Әлмәт районына һәм шәһәренә - 11 процент, Зәй районына һәм шәһәренә - 50 процент, Сарман районына - 67 процент, Тукай районына - 9 процент, Түбән Кама шәһәренә - 28 процент.

Чаллы шәһәре территориясендә 83000 мең сумлык капитал салуларны финанслау һәм социаль өлкәгә караган объектларны тоту өчен Чаллы шәһәре территориясендә җитештерелгән (башкарылган, күрсәтелгән) товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) өстәлгән бәяләргә салымның 50 процентын Чаллы шәһәре бюджетына тапшырырга.

Казан шәһәре территориясендә 243000 мең сумлык капитал салуларны финанслау өчен Казан шәһәре территориясендә җитештерелгән (башкарылган, күрсәтелгән) товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) өстәлгән бәяләргә салымның 14 процентын Казан шәһәре бюджетына тапшырырга.

20 статья. 1998 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында агымдагы чыгымнарны финанслау өчен ассигнованиеләрнең гомуми күләмен - 7600585 мең сум дип, үсеш бюджетын финанслау өчен капитал салуларны да кертеп, 5447983 мең сум, дип билгеләргә.

21 статья. 1998 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан ассигнованиеләрне түбәндәге максатларга юнәлтергә:

(мең сумнарда)

| | Барысы | шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | агымдагы чыгымнар бюджеты | үсеш бюджеты |
| 1. Дәүләт идарәсенә | 218882 | 218882 | |
| 2. Татарстан Республикасы Югары арбитраж судына | 3736 | 3736 | |
| 3. Халыкара эшчәнлеккә | 10404 | 10404 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. Хокук саклау эшчәнлегенә һәм иминлекне тәэмин итүгә, | 628720 | 481220 | 147500 |
| шул исәптән: 1997-1998 елларда Татарстан Республикасында җинаятьчелеккә каршы көрәш программасына | 50000 | 50000 | |
| 5. Фәнгә | 25000 | 21525 | 3475 |
| 6. Промышленность, энергетика һәм төзелеш | | | |
| - халыкка ягулык өчен дотациягә (каты ягулыкка һәм газга) | 40071 | 40071 | |
| - торак-төзелеш кооперативларына | 10000 | 10000 | |
| 7. Авыл хуҗалыгы | | | |
| - авыл хуҗалыгына | 1153900 | 1153900 | |
| - Ветеринария баш идарәсенә | 19100 | 19100 | |
| - җирләрнең уңдырышлылыгын күтәрүгә һәм аларны эрозиядән саклауга | 120000 | 120000 | |
| 8. Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау | | | |
| - урман хуҗалыгына | 88000 | 80000 | 8000 |
| - әйләнә-тирә табигать мохитен саклауга | 32000 | 12000 | 20000 |
| 9. Җир реформасы белән бәйле гамәлләргә чыгымнар | 32812 | 32812 | |
| 10. Азык-төлек товарлары буенча дәүләт заказын формалаштыруга чыгымнар (кире кайтару шарты белән) | 250000 | 250000 | |
| 11. Транспорт | | | |
| - автомобиль транспортына | 90859 | 49960 | 40899 |
| - су транспортына | 14510 | 14510 | |
| - һава транспортына | 6890 | 6890 | |
| - тимер юл транспортына | 30460 | 30460 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. Торак-коммуналь хуҗалыгы | 107437 | 107437 | |
| Торак фондын һәм социаль-мәдәни өлкә объектларын кабул итүгә һәм файдалануга кертүгә (3 нче кушымта) | 171000 | 171000 | |
| 13. Гадәттән тыш хәлләрне һәм табигый бәла-казаларны кисәтү һәм бетерү өчен | 4000 | 4000 | |
| 14. Мәгариф | 176409 | 155069 | 21340 |
| шул исәптән: | | | |
| Татар гуманитар институтына | 8800 | 8800 | |
| 15. Мәдәният һәм сәнгать | 8800 | 8800 | |
| - мәдәният һәм сәнгатькә | 203965 | 127078 | 76887 |
| -"Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруга | 6000 | 6000 | |
| - кинематографиягә | 15291 | 14291 | 1000 |
| 16. Массакүләм мәгълүмат чаралары | | | |
| - телевидениегә һәм радиотапшыруларга | 31000 | 29000 | 2000 |
| - көндәлек матбугатка һәм нәшриятларга | 33957 | 31036 | 2921 |
| 17. Сәламәтлек саклау һәм физик культура | | | |
| - сәламәтлек саклауга | 521871 | 508476 | 13395 |
| - санитария-эпидемиология күзәтчелегенә | 64221 | 60754 | 3467 |
| - Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Реабилитацияләү үзәгенә | 5000 | 4525 | 475 |
| - физик культурага | 30000 | 30000 | |
| 18. Социаль сәясәт | | | |
| - социаль тәэминат учреждениеләренә | 110871 | 104338 | 6533 |
| - яшьләр сәясәтенә | 9000 | 9000 | |
| - социаль яклау чараларына | 111313 | 111313 | |

76

| | | |
|---|---|---|
| 19. Башка чыгымнар | | |
| - Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең резерв фондына | 50000 | 50000 |
| - районнарга һәм шәһәрләргә финанс ярдәме (дотация) | 1251664 | 1251664 |
| - "КамАЗ" ААҖенә мөлкәткә салым түләү өлешендә ташламалар бирүгә бәйле рәвештә Чаллы шәһәре бюджетының төшеп калучы керемнәрен компенсацияләүгә | 58000 | 58000 |
| 20. Заем акчаларына хезмәт күрсәтүләргә | 555000 | 555000 |
| 21. Республиканың максатчыл программаларын гамәлгә ашыруга | | |
| - мәгарифкә - барысы | 14600 | 14600 |
| шул исәптән: | | |
| "Мәгарифне үстерүнең беренче чираттагы чаралары турында"гы максатчыл программага | 4600 | 4600 |
| "Ятим балалар" максатчан программасына | 10000 | 10000 |
| - Сәламәтлек саклауга - барысы | 52000 | 52000 |
| шул исәптән: | | |
| Туберкулезны кисәтү һәм аңа каршы көрәш буенча ведомствоара республика программасына | 20200 | 20200 |
| Татарстан Республикасында кешенең иммун-дефицит вирусы китереп чыгара торган авыруның таралуын кисәтү буенча максатчыл программага | 9600 | 9600 |
| Халыкка наркологик ярдәм күрсәтүне камилләштерү буенча республика максатчыл програмасына | 2900 | 2900 |
| Халыкка кардиологик ярдәм күрсәтүне үстерү буенча максатчыл программага | 2100 | 2100 |

| | | |
|---|---|---|
| "Бәла-казалар медицинасы республика хезмәтен камилләштерү" максатчыл программасына | 5000 | 5000 |
| Организмны бөердән тыш чистарту (ясалма бөер) ысуллары хезмәтен үстерүнең максатчыл программасына | 10000 | 10000 |
| Татарстан Республикасы территориясен кешеләр өчен аеруча куркынычлы йогышлы авырулар үтеп керүдән һәм таралудан саклау буенча республика максатчыл программасына | 2200 | 2200 |
| - Мәдәният - барлыгы | 23700 | 23700 |
| шул исәптән: | | |
| Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм торгызу буенча максатчыл программага | 16500 | 16500 |
| Татарстан Республикасының опера һәм балет сәнгатен үстерү максатчыл программасына | 7200 | 7200 |
| - Республика полиграфиясенә һәм китап нәшер итүгә ярдәм буенча максатчыл программага | 6300 | 6300 |
| - Инвалидларның мәгълүмат чыганакларыннан һәм инфраструктура объектларыннан тоткарлыксыз файдалану мөмкинлеген тәэмин итү программасына | 500 | 500 |
| - Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең дәүләт системасын үстерү буенча максатчыл программага | 5900 | 5900 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| - Югары лигадагы спорт командаларын тоту чыгымнарын өлешчә каплауга | 30000 | 30000 | |
| 22. Республика инвестиция программасына | 396255 | | 396255 |
| 23. Максатчыл бюджет фондлары чыгымнары | 6227970 | 1524134 | 4703836 |
| - Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды | 453700 | 381500 | 72200 |
| Татарстан Республикасы "Янгын куркынычсызлыгы" фонды | 90000 | 53160 | 36840 |
| - Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының ДАИ идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 30000 | 9292 | 20708 |
| - Татарстан Республикасы Юллар фонды | 2500000 | 444838 | 2055162 |
| - Татарстан Республикасы Экология фонды | 300000 | 131500 | 168500 |
| - Татарстан Республикасы Хосусыйлаштыру фонды | 612000 | 38030 | 573970 |
| - Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре (НИОКР) республика фонды | 552000 | 67250 | 484750 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| - Татарстан Республикасының минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 1130230 | 244774 | 885456 |
| - Республика сырхауханә кассасы | 140040 | 102542 | 37498 |
| - Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру фонды | 420000 | 51248 | 368752 |

**22 статья.** 1998 елга авыл хуҗалыгы өчен бюджет акчаларын бүлүне әлеге Законның 1 нче кушымтасы нигезендә 1293000 мең сум күләмендә расларга.

**23 статья.** 1998 елга үсеш бюджетының бюджет акчаларын бүлүне әлеге Законның 2 нче кушымтасы нигезендә 727455 мең сум күләмендә расларга.

Халык дедпутатларының җирле Советларына, һәр объект буенча сумманы күрсәтеп, капитал салулар объектлары исемлекләрен раслауны йөкләргә.

**24 статья.** 1998 елда дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны 218882 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

(мең сумнарда)

түбәндәгеләрнең эшчәнлеген финанслау өчен чыгымнар:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президентының, Президент Аппаратының | 21000 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, аның Аппаратының, даими эшләүче халык депутатларының | 21500 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларының депутат вәкаләтләрен башкаруга бәйле чыгымнарын каплауга | 546 |

Закон проектларын эшләүгә һәм аларга экспертиза үткәрүгә бәйле чыгымнарга 1000

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрен үткәрүгә бәйле чыгымнарга 2000

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитетының 1879

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 13470

Татарстан Республикасы министрлыкларының,дәүләт комитетларының, ведомстволарының һәм аларның органнарының 135754

Татарстан Республикасының Конституция күзәтү комитетының 500

Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең, 1560

шул исәптән: киткәннәре урынына Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар уздыруга 760

Архив учреждениеләрен финанслау чыгымнары 5473

"Дәүләт хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чыгымнары 14200

25 с т а т ь я. 1998 елга Татарстан Республикасының халыкара эшчәнлеген башкару өчен чыгымнарны 10404 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

Түбәндәгеләрнең эшчәнлеген финанслау өчен чыгымнар: (мең сумнарда)

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллегенә 5241

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Үзбәкстан Республикасындагы Даими вәкиллегенә | 470 |
| Татарстан Республикасының Азәрбайҗан Республикасындагы Даими вәкиллегенә | 367 |
| Татарстан Республикасының Свердловск өлкәсендәге Даими вәкиллегенә | 711 |
| Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиллегенә | 601 |
| Татарстан Республикасының Казагыстан Республикасындагы Тулы вәкаләтле вәкиллегенә | 293 |
| Татарстан Республикасының Франциядәге Тулы вәкаләтле вәкиллегенә | 1110 |
| Татарстан Республикасының Төркиядәге Тулы вәкаләтле вәкиллегенә | 576 |
| Татарстан Республикасының Вашингтон шәһәрендәге (АКШ) Даими вәкиленә | 435 |
| Татарстан Республикасының Чехия һәм Словакия Республикаларындагы Даими вәкиленә | 320 |
| Татарстан Республикасының Кипр Республикасындагы вәкиллегенә | 280 |

26 с т а т ь я. Бюджетта каралган гамәлләрне өзлексез финанслауны тәэмин итү йөзеннән,1998 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан районнар һәм шәһәрләр бюджетлары-

на 1251664 мең сум күләмендә дотация бүлеп бирергә, шул исәптән:

(мең сумнада)

| | |
|---|---|
| Азнакай районы | 7324 |
| Аксубай районы | 38941 |
| Актаныш районы | 42560 |
| Алексеевск районы | 29304 |
| Алабуга районы | 41358 |
| Апас районы | 26635 |
| Арча районы | 46672 |
| Әгерҗе районы | 37425 |
| Әлки районы | 30583 |
| Әтнә районы | 23063 |
| Балтач районы | 36396 |
| Балык Бистәсе районы | 37879 |
| Биек Тау районы | 9017 |
| Бөгелмә районы | 3350 |
| Буа районы | 33478 |
| Зеленодол районы | 32508 |
| Кайбыч районы | 16987 |
| Кама Тамагы районы | 21827 |
| Кукмара районы | 54894 |
| Лаеш районы | 27394 |
| Лениногорск районы | 17427 |
| Мамадыш районы | 57749 |
| Менделеев районы | 18685 |
| Минзәлә районы | 28049 |
| Мөслим районы | 26770 |
| Нурлат районы | 13152 |
| Питрәч районы | 26599 |
| Саба районы | 32430 |
| Спас районы | 34539 |
| Тәтеш районы | 40520 |
| Теләче районы | 19375 |
| Түбән Кама районы | 70640 |
| Чирмешән районы | 21408 |
| Чистай районы | 32398 |

| | |
|---|---|
| Чүпрәле районы | 29059 |
| Югары Ослан районы | 19402 |
| Ютазы районы | 2985 |
| Яңа Чишмә районы | 16846 |
| Алабуга шәһәре | 32907 |
| Зеленодол шәһәре | 69153 |
| Чистай шәһәре | 43976 |

27 с т а т ь я. 1998 елга Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү фондының бюджетын керемнәр буенча 453700 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 453700 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда Халыкны эш белән тәэмин итү фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбенә туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Социаль салым | 389700 |
| Башка төрле керемнәр | 64000 |

1998 елда, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм башка хуҗалык итүче субъектлар өчен, иминләштерү кертемнәрен түләү тәртибен, күләмен, шартларын һәм түләүдән азат итү шартларын 1997 елга билгеләнгәнчә итеп калдырырга.

1998 елда Халыкны эш белән тәэмин итү фонды акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Эшсезлек буенча пособие түләргә | 169300 |
| шул исәптән социаль яклау чараларына түләүләргә | 21433 |
| Эшсезләрне һәм шөгыле булмаган гражданнарны һөнәргә өйрәтүгә | 18300 |

| | |
|---|---|
| Вакытлы эш белән тәэмин итүне финанслауга - барлыгы | 36700 |
| шул исәптән: | |
| - балигъ булмаган гражданнарны эш белән тәэмин итү өчен вакытлы эш урыннары булдыруга | 20000 |
| - эшсез гражданнарның эш белән тәэмин ителүен оештыруга | 14300 |
| - яшьләрнең эш белән тәэмин ителүен оештыруга ("Яшьләр практикасы") | 2400 |
| Вакытыннан алда пенсияләр түләүгә | 25300 |
| Эш урыннары булдыру һәм аларны саклауда эш бирүчеләргә ярдәм күрсәтүгә, барлыгы: | 32500 |
| шул исәптән: | |
| Татарстан Республикасы кече эшкуарлыгына ярдәм итүне оештыруга | 4000 |
| Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү органнарын тотуга | 41000 |
| Максатчан (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына түләүләргә | 3059 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары | 19485 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына түләүләргә | 3000 |
| Башка чыгымнарга | 105056 |

**28 статья.** 1998 елга Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәтләре идарәсенең "Янгын куркынычсызлыгы" (алга таба "Янгын куркынычсызлыгы" фонды) агымдагы махсус счеты бюджетын керемнәр буенча 90000

мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 90000 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда "Янгын куркынычсызлыгы" фонды бюджетының керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбенә туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Берләштерелгән түләүләр буенча | 90000 |

1998 елда "Янгын куркынычсызлыгы" фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Шәһәрләрдә һәм районнарда Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте бүлекчәләренә 25 процент акча күчерүләргә | 22500 |
| Янгын деполарына һәм торак биналарга капиталь ремонт ясауга һәм капиталь төзелеш алып баруга | 24340 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы бюджеттан тыш Дәүләт торак фондына акча күчерүләргә | 1500 |
| Янгын сүндерү техникасын, автотранспортны тотуга, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү техникасы сатып алуга | 11000 |
| Максатчан (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына акча күчерүләргә | 278 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына акча күчерүләргә | 4500 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары шул исәптән: | 4500 |

районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру программасын финанслауга 1800

Башка чыгымнарга 21382

29 с т а т ь я. 1998 елга Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының дәүләт автоинспекциясе идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды (алга таба - Юл хәрәкәте иминлеге фонды) бюджетын керемнәр буенча 30000 мең сум, чыгымнар буенча 30000 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда Юл хәрәкәте иминлеге фондының бюджет керемнәре түбәндәге чыганаклардан туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Штрафлар | 30000 |

1998 елда Юл хәрәкәте иминлеге фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Юл хәрәкәте иминлеге фондының шәһәр һәм район бүлекчәләренә акча күчерүләргә | 10075 |
| Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларына | 9933 |
| Социаль яклауга түләүләргә | 1650 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына акча күчерүләргә | 1500 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына акча күчерүләргә | 700 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтүгә акча күчерүләргә | 1500 |
| шул исәптән: | |
| Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру программасын финанслауга | 600 |

| | |
|---|---|
| Максатчыл (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына акча күчерүгә | 142 |
| Башка чыгымнарга | 4500 |

30 с т а т ь я. 1998 елга Татарстан Республикасының Юллар фонды бюджетын керемнәр буенча - 2500000 мең сум, чыгымнар буенча - 2500000 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда Юллар фонды бюджетының керемнәре түбәндәге чыганаклар хисабына туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым | 1543440 |
| Ягулык-майлау материаллары сатуга салым | 422770 |
| Транспорт хуҗаларыннан салым | 60140 |
| Автотранспорт сатып алуга салым (гражданнар шәхси файдалануга сатып алган җиңел автомобильләрдән башка) | 158805 |
| Кире кайтарып бирү шарты белән биреп торылган чималдан нефть эшкәрткәндә ягулык-майлау материаллары сатуга салым | 314845 |

1998 елда Юллар фонды акчалары түбәндәге максатларга тотыла:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Казан халыкара аэропортын реконструкцияләүгә | 162900 |
| шул исәптән: Казан халыкара аэропорты һава юллары идарәсен реконструкцияләүгә | 75000 |
| Максатчыл (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына акча күчерүгә | 1776 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына акча күчерүгә | 125000 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары | 82429 |
| шул исәптән Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру программасын финанслауга | 50000 |
| Гомуми файдалану юлларында юл төзү эшләренә | 1388995 |
| Кама елгасы аша күпер төзелешенә | 300000 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына акча күчерүгә | 30000 |
| Социаль яклау чаралары өчен акча күчерүгә | 137500 |
| Башка чыгымнарга, | 271400 |
| шул исәптән 1997 елга кредитор бурычларына | 265900 |

31 **с т а т ь я.** 1998 елга Татарстан Республикасы Экология фонды (алга таба - Экология фонды) бюджетын керемнәр буенча 300000 мең сум, чыгымнар буенча 300000 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда Экология фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар хисабына туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Әйләнә-тирә мохитне пычраткан өчен түләнгән акчалардан | 279600 |
| Табигый байлыкларны торгызу өчен түләүләрдән | 8400 |
| Башка керемнәрдән | 12000 |

1998 елда Татарстан Республикасы Экология фонды акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча максатчыл программаларны гамәлгә ашыруга | 177900 |
| Татарстан Республикасының табигатьне саклау хезмәтләре эшчәнлеген тәэмин итүгә | 56700 |
| Максатчыл (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына акча күчерүгә | 3300 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына акча күчерүгә | 14400 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары | 15000 |

шул исәптән:

| | |
|---|---|
| Районнарны, шәһәрләрне, авылларны газлаштыру программасын финанслауга | 6000 |
| Социаль яклау чаралары өчен акча күчерүгә | 16500 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына акча күчерүләргә | 5600 |
| Фонд советы карарлары буенча табигатьне саклау гамәлләре резервына | 10600 |

32 с т а т ь я. 1998 елга Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды (алга таба - Хосусыйлаштыру фонды) бюджетын керемнәр буенча 112000 мең сум, чыгымнар буенча 612000 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда Хосусыйлаштыру фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбенә туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Мөлкәт сатудан килгән керемнәр | 3500 |
| Хезмәт коллективлары тарафыннан акцияләр сатып алудан керемнәр | 3500 |
| Кыйммәтле кәгазьләр сатудан (акцияләрнең дәүләт өлеше) | 90000 |
| Башка керемнәр (аренда, дивидендлар, лицензия һәм коммиссия җыемнары) | 15000 |

1998 елда Хосусыйлаштыру фонды акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Предприятиеләргә кредит бирүгә | 38370 |
| Заем акчаларын кайтарып бирүгә | 30000 |
| Акцияләрне залогка салу бәрабәренә җәлеп ителгән ресурслар исәбенә үсеш инвестиция фондын туплауга | 500000 |
| шул исәптән: | |
| - Алабуга автомобиль заводын инвестицияләүгә | 350000 |
| кайтарып бирү шарты белән | 216000 |
| кайтарып бирмәү шарты белән | 134000 |
| - кече бизнеска ярдәм итүгә | 50000 |
| Бөлгенлеккә тәшү (банкротлык) эшләре буенча республика агентлыгы аппаратын тотуга | 2500 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары | 5600 |
| шул исәптән: | |
| Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру программасын финанслауга | 2240 |
| Социаль яклау чаралары өчен акча күчерүгә | 6160 |
| Максатчыл (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына акча күчерүләргә | 2130 |
| Башка чыгымнарга | 21640 |
| шул исәптән: | |

Президентның 1995 елның 7 мартындагы VII-149 номерлы Указы нигезендә депозитар

хезмәт күрсәтүләр әчен түләүләргә

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына акча күчерүләргә | 5600 |

33 статья. 1998 елга гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре (НИОКР) республика фондының бюджетын керемнәр буенча - 552000 мең сум, чыгымнар буенча 552000 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда НИОКР фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбенә туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Үзәкләштерелгән өлешне туплауның исәпләү күләме (түләмнәрнең 0,75 проценты) | 240000 |
| Үзәкләштерелмәгән өлешне туплауның исәпләү күләме (предприятие карамагында кала) | 250000 |
| Кайтарып бирү шарты белән бүлеп бирелгән кредитлардан һәм алар буенча процентлардан түләнергә тиешле акчалар | 62000 |

1998 елда НИОКР фонды акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Инвестиция программаларын һәм проектларын финанслауга | 135000 |
| Фәнне өстенлекле юнәлешләрдә үстерү буенча дәүләт программасына | 85000 |
| Үзәкләштерелмәгән өлешләр исәбенә предприятиеләрнең фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре чыгымнарына | 250000 |

| | |
|---|---|
| Максатчыл (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына акча күчерүләргә | 2555 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына акча күчерүгә | 12300 |
| НИОКР фондының устав һәм фәнни-оештыру эшчәнлеген финанслауга | 7695 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына акча күчерүләргә | 14750 |
| Социаль яклау чаралары өчен акча күчерүгә | 13500 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары | 12000 |
| шул исәптән: Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру программасын финанслауга | 4800 |
| Башка чыгымнарга | 19200 |

34 с т а т ь я . 1998 елга Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды бюджетын керемнәр буенча 1130230 мең сум, чыгымнар буенча - 1130230 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондының бюджет керемнәре түбәндәге чыганаклар хисабына туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Минераль чимал базасын торгызуга салым | 830230 |
| Дебиторлык бурычы | 300000 |

1998 елда Татарстан Республикасы Минераль ресурслар запасын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Файдалы каты казылмалар өлкәсендә фәнни-тикшеренү һәм геология-разведка эшләрен финанслауга | 121089 |
| Углеводород чималы өлкәсендә фәнни-тикшеренү һәм геологик-эзләнү эшләрен финанслауга | 484356 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары шул исәптән: | 56512 |
| Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру программасын финанслауга | 22605 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына акча күчерүләргә | 56512 |
| Социаль яклау чараларына акча күчерүләргә | 62163 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына акча күчерүләргә | 53400 |
| Максатчыл (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына акча күчерүгә | 497 |
| 1997 ел өчен кредит бурычын түләү өчен акча күчерүләргә | 226611 |
| Башка чыгымнарга | 69090 |

35 **с т а т ь я.** 1998 елга Республика сырхауханә кассасы бюджетын керемнәр буенча 140040 мең сум, чыгымнар буенча 140040 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда Республика сырхауханә кассасының бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Территория сырхауханә кассаларыннан кергән акчалар - 25% | 140040 |

1998 елда Республика сырхауханә кассасы акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Мәҗбүри медицина иминияте Федераль фондына акча күчерүләргә | 31145 |
| Резерв фондына | 33610 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары | 7002 |
| Максатчыл программалар фондына | 3888 |
| Максатчыл (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына акча күчерүләргә | 1563 |
| Иминиятне тәэмин итү фондына | 55030 |
| Башка чыгымнарга | 7802 |

36 **с т а т ь я.** Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру фондының (алга таба - Газлаштыру фонды) 1998 елга бюджетын керемнәр буенча 420000 мең сум, чыгымнар буенча 420000 мең сум күләмендә расларга.

1998 елда Газлаштыру фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар хисабына туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Газ кулланучылар 90 процентын түләгән очракта, барлык салымнарны һәм җыемнарны тотып калып, түләнгән акчаның 15 процентыннан акча күчерүләр | 150000 |
| Заем акчалары | 150000 |
| Җылылык һәм электр энергиясе өчен бирелгән бурычлар исәбенә керүче акчалар | 120000 |

1998 елда Газлаштыру фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Инвестицияләүне, магистраль челтәрләре, кварталлар эчендәге һәм ишек алларындагы газ челтәрләре төзүне дә кертеп, Татарстан Республикасы авылларын, шәһәрләрен һәм эшчеләр поселокларын газлаштыру программасын гамәлгә ашыруга | 368752 |
| шул исәптән: | |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына акча күчерүләргә | 8500 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына акча күчерүләргә | 13500 |
| Максатчыл (бюджеттан тыш) фондлар белән идарә итү департаментына акча күчерүләргә | 1148 |

Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары 13500

Социаль яклау өчен акча күчерүләргә 23100

37 с т а т ь я . Татарстан Республикасы республика бюджетының әйләнештәге касса акчасын 1999 елның 1 гыйнварена 400000 мең сум күләмендә расларга.

38 с т а т ь я. 1998 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының тулы күләмдә финанслана торган яклanучан агымдагы чыгымнарының түбәндәге исемлеген расларга: мәҗбүри медицина һәм социаль иминләштерүгә кертемнәрне һәм Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына һәм Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегенә түләүләрне исәпкә алып, хезмәт хакы; стипендияләр; дәүләт пособиеләре, балаларга пособиеләр түләү һәм мәктәп балаларын туклandыруга дотацияләр, халыкка башка социаль түләүләр һәм компенсация түләүләре; туклану; медикаментлар һәм яраларны бәйләү чаралары сатып алу; хезмәт хакы түләү өлешендә җирле бюджетларга күчерелүче дотацияләр.

39 с т а т ь я . 1998 елга республика бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итүче, шулай ук аның керем базасын киметүче законнар, норматив-хокукый актлар Татарстан Республикасының республика бюджетында тиешле өстәмә керемнәр булганда һәм (яисә) 1998 елгы Татарстан Республикасы республика бюджетының конкрет бюджет статьялары буенча чыгымнар кимегәндә генә кабул ителә.

40 с т а т ь я. 1998 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Милли банкы Татарстан Республикасының республика бюджеты чыгымнарын һәм керемнәрен исәпкә алу, башкару системасын оештыруны һәм аның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә тиеш. 1998 елда Татарстан Республикасы бюджетын үтәүнең казначылык системасына күчүне гамәлгә ашырырга тиеш.

Бюджетларның касса үтәлеше буенча гамәлләре, комиссион түләүләр алынмаган килеш, Татарстан Республикасы Милли банкы яки Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкаләт биргән банклар та-

98

рафыннан башкарыла.

41 **с т а т ь я.** Татарстан Республикасы республика бюджетының кайбер бүлекләре буенча 1997 елда җитәрлек дәрәҗәдә финансланмау бары тик әлеге Законның 21 статьясында билгеләнгән 1998 елгы Татарстан Республикасы республика бюджеты ассигнованиеләре хисабына һәм шул чикләрдә генә компенсацияләнә.

42 **с т а т ь я.** Тиешле норматив-хокукый актлар кабул ителгәнче, "Дәүләт хезмәте турында"гы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3,8,11 пунктларын, 15 статьясын гамәлгә кертүгә бәйле чыгымнарны түләмәскә, моңа элек кабул ителгән законнар нигезендә дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү, матди һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү шартларына бәйле чыгымнар керми.

43 **с т а т ь я.** Татарстан Республикасы республика бюджетының предприятиеләргә һәм оешмаларга, кире кайтарып бирмәү һәм кире кайтарып бирү шартларында бирелә торган акчаларын башка максатларда файдалану әлеге суммаларны кайтарып алу әчен һәм Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге исәпкә алу ставкаларының икеләтелгән күләмендә штраф салу өчен нигез була.

Татарстан Республикасы республика бюджетыннан кире кайтару шарты белән бирелә торган акчаларны вакытында кире кайтармаганда барлык төр дәүләт ярдәме, шул исәптән салым түләмнәрен закон нигезендә кичектереп тору кыскартыла яки туктатыла.

Татарстан Республикасы республика бюджетының кире кайтару шарты белән бирелгән акчаларыннан файдаланган өчен төп бурыч акчаларын һәм шулай ук процентларны түләүдә соңга калганда һәр соңга калган көн өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге исәпкә алу ставкаларының өч йөздән бер өлеше күләмендә пеня алына.

44 **с т а т ь я.** Татарстан Республикасының республика бюджетына керемнәр арттырып җыелганда, алар дәүләт бурычларын түләү өчен тотыла.

45 с т а т ь я . Максатчыл дәүләт бюджеты фондларына керемнәр арттырып җыелганда, алар әлеге Законның 27-36 статьяларында билгеләнгән пропорцияләрдә чыгымнар өчен тотыла.

46 с т а т ь я . Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көннән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре
1997 елның 27 декабре
№ 1445